# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Татар Әхтиялы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

06.04.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2024 елның 26 мартындагы 1 номерлы 2023 елның 28 ноябрендәге 108 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 28 ноябрендәге 107 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында карары нигезендә

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2023 елның 28 ноябрендәге 108 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 28 ноябрендәге 107 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр үзгәрешләр кертергә һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә.

1) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Татар Әхтиялы авылында яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру-3(өч) данә)

2) Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татар Әхтиялы авылына 1 (бер) данә су насосы сатып алу);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү ( Татар Әхтиялында үлән чабу

өчен триммер сатып алу һәм үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү )

4) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, Урман урамында юлга вак таш җәю һәм Татар Әхтиялы торак пунктында вак таштан соң юлны тигезләү буенча эш өчен түләү).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru "Турай авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгы ____________ Г.Б. Куляшова
(имза) (имзаның аңлатмасы)